**РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом17,с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22,факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ № ______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын җайга салынмый торган тарифлар буенча раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын кушымта нигезендә җайга салынмый торган тарифлар буенча расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

2.1. Актаныш муниципаль районы территориясе буенча пассажир транспортының автобус маршрутлары хәрәкәте графигын билгеләнгән тәртиптә расларга;

2.2. җайга салынмый торган тарифлар буенча муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар һәм тиешле маршрутлар карталарын алу хокукына ачык конкурс үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 октябрендәге ПР-250 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче И.И.Габдулхаев